| МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

№ 124/о

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«06» 08 2018

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 202/о номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

1.Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 202/о номерлы боерыгына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр И.Ә.Файзуллин

ОТДЕЛ ОРГАНИЗАЦИОННО-ПРОТОКОЛЬНОЙ РАБОТЫ, КОНТРОЛЯ И ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2018 елның 06 августындагы 124/о номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 202/о номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 202/о номерлы боерыгында:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза тәэмин итүнең өстәмә гарантияләре һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу турында» 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы, «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза тәэмин итүнең өстәмә гарантияләре һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу турында» 2017 елның 29 июнендәге ПУ-575 номерлы Указын тормышка ашыру чаралары турында» 2017 елның 15 августындагы 580 номерлы карарлары нигезендә боерык бирәм:»;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибендә:

1.5 пунктның «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) актны (акт проектын) башка норматив хокукый актларга үзара бәйләнештә бәяләү;»;

3.1-3.3 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Министрлыкның рәсми бастырып чыгарылган, Министрлык тарафыннан эшләнә торган һәм «Татарстан Респбуликасы Рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы кысаларында аларга коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм иҗтимагый фикер алышу максатларында норматив хокукый актларның проектларын урнаштыру өчен булдырылган мәгълүмат ресурсында http://tatarstan.ru/regulation (алга таба – Мәгълүмат ресурсы) урнаштырылган актлары һәм актлары проектлары коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып тора.

3.2. Министрлыкның Министрлык тарафыннан эшләнә торган актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен Министрлыкның акт проектын әзерләү өчен җаваплы булган структур бүлекчәсе, акт проекты карау өчен юридик бүлеккә җибәрелгән көнгә туры килә торган эш көне эчендә, эксперт бәяләмәләрен җибәрү өчен адресын (шул исәптән электрон почта адресын), шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм тәмамлау даталарын күрсәтеп, акт проектын Мәгълүмат ресурсында урнаштыруны тәэмин итә.

3.3. Министрлыкның Министрлык тарафыннан эшләнә торган актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру срогы аларны Мәгълүмат ресурсына урнаштырган көннән башлап кимендә биш эш көне тәшкил итә.».